МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 48/о

«07» 05 2019

БОЕРЫК

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 21 июлендәге 122/о номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

**Боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 21 июлендәге 122/о номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 1 пунктындагы икенче абзацта "җиләк-җимеш, яшелчә бакчачылыгы, дача кулланучылар кооперативы" сүзләрен төшереп калдырырга;

Тәртипкә 1 нче кушымтада "җиләк-җимеш, яшелчә бакчачылыгы, дача кулланучылар кооперативы" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы Т.В.Титовага бу боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгындагы дәүләт граждан хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин